ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.12.2024 п.г.т.Алексеевское № 602

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 29.09.2021 ел, №358 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында

**карар бирәм:**

1. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 29.09.2021 ел, № 358 карары белән расланган Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

- 3.3.3.4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3.4. Регламентның 3.3.3.1, 3.3.3.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

Регламентның 3.3.3.1., 3.3.3.3. пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны үтәү кысаларында, һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә, ул пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә.»

- 3.4.5. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Регламентның 3.4.2, 3.4.4, 3.4.5 пунктларында күрсәтелгән процедураларны техник мөмкинлек булганда башкару дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, шул исәптән гаризаны регламентның 2.13 пункты нигезендә теркәгән вакыттан алып автомат режимда башкарыла.

Регламентның 3.4.2, 3.4.4., 3.4.5. пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны үтәү кысаларында һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле булганнарның пространство белешмәләренең милли системасы эшләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»

- 3.5.6. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.5.6. Регламентның 3.5.3-3.5.5 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлеге булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.5.3-3.5.5 пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны үтәү кысаларында һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле булганнарның пространство белешмәләренең милли системасы эшләвен тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.».

- 3.5 нче пунктны түбәндәге эчтәлекле 3.5.7 пунктчасы белән тулыландырырга:

«3.5.7. Регламентның 3.5 нче пунктта күрсәтелгән буенча административ процедураларны башкаруның максималь вакыты, 14 эш көне, җир кишәрлеге бирү турында хәбәр басылып чыккан очракта – 47 эш көне.».

- 3.6.2. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2. Документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасы документациясен алып бару ярдәмче системасына һәм (яисә) шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасына муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә белешмәләрне теркәүне һәм кертүне тәэмин итә;

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) электрон хезмәттәшлек юлы белән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен Палатада яисә КФҮ тә алу мөмкинлеге турында Республика порталы аша хәбәр итә.

Процедураларны үтәү техник мөмкинлекләр булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

Шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган Административ процедуралар Башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи заты (Башкарма комитет) тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне (бирүдән баш тартуны) раслый торган документка имза салынган көннән алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат системаларында белешмәләрне урнаштыру, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып тора.».

- 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Төзелгән гарызнамәне формат-логик тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче гарызнамәнең электрон рәвешендәге һәр кырын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал сорауның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры сорауның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.».

- 2.10. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә каралган хезмәтләрне күрсәтүдә катнашучы оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле экспертлар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге.

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.».

- 3 нче бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:

«Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Бүлектә дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары булырга тиеш, аларда гомуми билгеләр белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә, шул исәптән алар сорап мөрәҗәгать иткән дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенә карата күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибе кертелергә тиеш.».

- Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга,түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына 1 нче кушымтаның 16 пунктының «Мөрәҗәгать итүче» графасында «әлеге күчемсез мөлкәт объектлары бирелде» сүзләрен «дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге биналар, корылмалар арендага бирелде»сүзләренә алмаштырырга.

- Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына 1 нче кушымтаның 16 пунктының «Мөрәҗәгать итүче» графасында «белгечлекләр буенча,» сүзләрен «һөнәрләр, белгечлекләр, 2, сүзләренә, «еллар;» сүзен «еллар. Россия Федерациясе субъекты законында мондый гражданнарның торак урыннарына мохтаҗлар сыйфатында исәптә торырга яисә әлеге исәпкә кую өчен нигезләргә ия булырга тиешлеге, шулай ук мондый гражданнарның әлеге муниципаль берәмлектә индивидуаль торак төзелеше яисә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен бирелгән башка җир кишәрлекләренә милек хокукы булмау турындагы таләп каралырга мөмкин.».сүзләренә алмаштырырга.

- Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү

буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына 1 нче кушымтага 58.1 һәм 58.2 пунктларын (Кушымта) өстәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе Э.Н. Павловага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
25.12.2024 ел, № _602_
карарына кушымта

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 58.1. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 4.1 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | дини оешмаларга кырык тугыз елга кадәр срокка, күрсәтелгән җир кишәрлекләрендә милек хокукындагы дини яисә хәйрия билгеләнешендәге биналар, корылмалар урнашу шарты белән, әгәр күрсәтелгән җир кишәрлекләре әйләнештә чикләнгән булса һәм (яисә) әлеге дини оешмаларга милеккә бирелә алмаса | Дини оешмага түләүсез файдалану хокукында бирелгән биналар, корылмалар урнашкан җир кишәрлеге | Әгәр мондый бинага хокук, корылма ЕГРН да теркәлмәгән булса, бинадан, корылмадан түләүсез файдалану шартнамәсе<br><br>Әгәр мондый җир кишәрлегенә хокук ЕГРН да теркәлмәгән булса (җир кишәрлегенә тиешле хокуклар булганда), сорала торган җир кишәрлегенә мөрәҗәгать итүченең хокукларын таныклаучы (билгеләүче) документлар<br><br>Мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүчеләрнең) сорала торган җир кишәрлегендә урнашкан барлык биналар, корылмалар исемлеген үз эченә алган, |
| 58.2. | Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 4.2 пунктчасы | Түләүсез файдалануга | коммерциягә карамаган оешмаларга күрсәтелгән җир кишәрлекләрендә түләүсез файдалану хокукындагы һәм дәүләт яисә муниципаль милектәге биналар, корылмалар урнашу шарты белән, мондый биналарга, | Дини оешмага түләүсез файдалану хокукында бирелгән биналар, корылмалар урнашкан җир кишәрлеге | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | корылмаларга хокуклар туктатылганчы | | мөрәҗәгать итүчегә тиешле хокукта караган биналарның, корылмаларның кадастр (шартлы, инвентарь) номерларын һәм адреслы ориентирларын күрсәткән хәбәр<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир кишәрлеге турында)ЕГРНнан өземтә<br><br>* Күчемсез милек объекты турында (сорала торган җир кишәрлегендә урнашкан бина һәм (яисә) корылма турында) ЕГРНнан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торучы юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |